**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында гражданнар җыены карары**

21 ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2021 елда Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукы булган балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Лашчы тимер юл разъезды авылында чишмәне һәм каты көнкүреш калдыкларын җыю мәйданчыгын төзекләндерү эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы _________ М.К. Истиев

Халык җыены секретаре _________ И.Ю. Камалтдинова